ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 243 от «14» 06 2023 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 24 декабрендәге 607 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Мамадыш районы прокурорының 2023 елның 10 маендагы № 02-01-19-2023 номерлы тәкъдимен караганнан соң, "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 24 декабрендәге "Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын яңа редакциядә раслау турында" 607 номерлы карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Әлеге Карар белән расланган Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар үткәрмичә генә арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1 нче кушымтасына түбәндәге эчтәлекле 23_3 пунктча өстәргә:

"23_3) милли парк чикләрендә урнашкан һәм милли паркта рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында килешүдә каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле федераль милектәге җир кишәрлеге, шундый килешү төзегән затка;";

1.2. Карарның преамбуласында "Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында" 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән" сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның 1.1 пункты 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының http://mamadysh.tatarstan.ru// адресы буенча рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче О.Н.Павлов